РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

САБИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН

СОВЕТ САТЫШЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

422070, Республика Татарстан, Сабинский район,
С.Сатышево, ул. Ленина, 17Б
тел. (8262) 2-24-16

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ

САТЫШ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422070, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Сатышавылы, Ленин урамы, 17Б йорт
тел. (8262) 2-24-16

e-mail: Sat.sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ
13.11.2024

КАРАР
№26

Саба муниципаль районы Сатыш
авыл җирлеге Советының 27.04.2018 №10
«Татарстан Республикасы Саба муниципаль
районы Сатыш авыл җирлеге җирле үзидарә
органнарының депутатларына, сайланулы вазыйфаи
затларына һәм муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт
өчен түләү шартлары турында Нигезләмә» карарына
үзгәрешләр кертү хакында

Җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең социаль гарантияләрен тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 25.09.2024 елгы №829 «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 28.03.2018 елгы №182 «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларының, Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләр органнары, муниципаль хезмәткәрләр хезмәтенә түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында карарына үзгәрешләр кертү хакында» карары нигезендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Сатыш авыл җирлеге

КАРАР БИРӘ:

1. Саба муниципаль районы Сатыш авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Сатыш авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының һәм муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында Нигезләмә» нең 27.04.2018 елгы № 10 карарына (Советның 09.11.2020 ел №13, 19.10.2022 ел, №15, 19.12.2022 ел.№21, 26.08.2024 ел №13 карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгече вазыйфаи окладын 13990 сум күләмендә расларга»;

1.2. Карарга 1 нче кушымтаны әлеге карарның 1 нче кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Сатыш авыл җирлеге җирле үзидарә органнарына әлеге карар белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып, 2025 елның 1 гыйнварыннан гамәлгә кергән яңа штат расписаниеләрен расларга.

3. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына җирле бюджетларда каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның гамәлдә булуын 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә җәелдерергә.

5. Әлеге карарны "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Сатыш авыл җирлегенең рәсми сайтында: http://saby.tatarstan.ru/satish адресы буенча бастырып чыгарырга.

Сатыш авыл җирлеге башлыгы Ф.Ф.Шафигуллин

Кушымта №1
Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Сатыш авыл җирлеге Советының 13.11.2024 ел № 26 карары

**Саба муниципаль районы Сатыш авыл җирлеге башлыгы, депутатлар, Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы сайланулы вазыйфаи затларына акчалата бүләк күләме**

| Вазыйфалар исемнәре | Акчалата бүләк күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Авыл җирлеге башлыгы | 19173 |
| Депутатлар | 13990 |
| Сайланулы вазыйфаи затлар | 13990 |